| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Киекле ав. **КАРАР**

«05» ноябрь 2024 ел № 7

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылында Үрнәк авылы, Нагорная урамы, 40 йорт адресы буенча урнашкан йорт янында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 22 ноябрелэнә Үрнәк авылында яшәүче гражданнар өчен 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Үрнәк авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

3. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Киекле авыл җирлегендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш 2025 елда үзара салым тәртибендә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- эчәр су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Үрнәк торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, шул исәптән таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу ,ташу, салу), чокырларны ремонтлау (коелган асфальт);

- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күплəп ял итә торган урыннары (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның күплəп ял итә торган башка урыннары) товарларын (эшләрен, хезмәт күрсәтүләрен) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү);

- Үрнәк торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- Үрнәк торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләп алу, төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Үрнәк авылының мәгълүмат стендларында халык җыенын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы Л.И. Кашапова